# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Уразлы авылында 2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2023 елның 07 декабре №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлегенең Уразлы авылында гражданнар җыены:

1.2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән вак ташлар сатып алу, ташу, салу, грейдировкалау, юлларны кышкы чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аңа эленеп торучы җиһазлар өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән төзелеш материаллары сатып алу, язгы-көзге чорда чүп үләннәрен кисү, ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аңа эленеп торучы җиһазлар өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү);

- ремонт, коймалар төзү, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (шул исәптән койма ремонтлау, төзелеш материаллары, спил сатып алу, коры агачларны, куакларны кисү, зират территориясен җыештыру һәм чистарту, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Уразлы авылы, Тынычлык урамы, 7 нче йорт, административ бина; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль

районы Уразлы авыл җирлеге башлыгы М. Г. Хәмидуллин